ГОСУДАРСТВЕННАЯ ИНСПЕКЦИЯ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ПО ОБЕСПЕЧЕНИЮ
ГОСУДАРСТВЕННОГО КОНТРОЛЯ
ЗА ПРОИЗВОДСТВОМ, ОБОРОТОМ И
КАЧЕСТВОМ ЭТИЛОВОГО СПИРТА,
АЛКОГОЛЬНОЙ ПРОДУКЦИИ
И ЗАЩИТЕ ПРАВ ПОТРЕБИТЕЛЕЙ
(Госалкогольинспекция Республики Татарстан)

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
ЭТИЛ СПИРТЫ, АЛКОГОЛЬЛЕ
ПРОДУКЦИЯ ҖИТЕШТЕРУ, ӘЙЛӘНЕШЕ
ҺӘМ СЫЙФАТЫ ӨЛКӘСЕНДӘ ДӘҮЛӘТ
КОНТРОЛЕН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ
КУЛЛАНУЧЫЛАРНЫҢ ХОКУКЛАРЫН
ЯКЛАУ БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ ИНСПЕКЦИЯСЕ
(Татарстан Республикасы дәүләт алкоголь инспекциясе)

# БОЕРЫК

25.07.2024 № 10-07/95

Казань ш.

Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең «Административ штрафларны түләүгә өметсез дип тану турында Карар кабул итү тәртибен раслау хакында» 2016 елның 19 декабрендәге 12-07/127 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе тарафыннан администрацияләнә торган административ штрафларны түләтүгә өметсез дип тану турында карар кабул итү Тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

1. Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең «Административ штрафларны түләүгә өметсез дип тану турында Карар кабул итү тәртибен раслау хакында» 2016 елның 19 декабрендәге 12-07/127 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясе тарафыннан администрацияләнә торган административ штрафларны түләтүгә өметсез дип тану турында карар кабул итү Тәртибенә (Татарстан Республикасы Дәүләт алкоголь инспекциясенең 2020 елның 25 июнендәге 10-07/46 номерлы һәм 2022 елның 28 апрелендәге 10-07/52 номерлы боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Билгеләнгән вакытта бюджетка түләнмәгән түләүләр (бюджетка түләүләр буенча бурыч) түләнүгә өметсез дип танылу очраклары:

1) административ штраф түләүче физик затның - Россия Федерациясе гражданлык процессуаль законнарында билгеләнгән тәртиптә вафат булуы яисә аны вафат булган дип игълан ителүе;

2) «Бөлгенлек (банкротлык) турында» 2002 елның 26 октябрендәге 127-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гражданның, индивидуаль эшкуарның банкротлык процедурасын бюджетка түләүләр буенча бурыч

өлешендә тәмамлау, аны түләү бурычын үтәүдән ул күрсәтелгән Федераль закон нигезендә азат ителүе;

3) оешманың мөлкәте җитмәү һәм (яисә) аны гамәлгә куючылар (катнашучылар) тарафыннан Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән чикләрдә һәм тәртиптә түләп бетерү мөмкин булмау сәбәпле бюджетка түләүләр буенча юкка чыгарылмаган бурыч өлешендә бюджетка түләүләр түләүче оешманың юкка чыгарылуы;

4) җәзага хөкем ителгәннәргә карата штраф яки суд тарафыннан карар кабул итү рәвешендә амнистия яки ярлыкау турында актлар куллану, шуның нигезендә бюджет керемнәре администраторы бюджетка түләүләр буенча бурычны түләтү мөмкинлеген югалтуы, шул исәптән аны түләтүнең билгеләнгән срогы тәмамлануга бәйле булуы;

5) «Башкару эше турында» 2007 елның 2 октябрендәге 229-ФЗ номерлы Федераль законның 46 статьясындагы 1 өлешенең 3 яисә 4 пунктында каралган нигез буенча башкарма документны түләтүчегә кире кайтарганда, әгәр бурыч барлыкка килгән көннән бурычлыга карата бөлгенлек турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән таләпләр күләменнән артмаса, башкаручы суд приставы тарафыннан башкару эшен тәмамлау турында карар чыгарылган булса (банкротлык) банкротлык турындагы эш буенча производство ачу өчен биш елдан артык вакыт узган булуы;

6) банкротлык турындагы эштә кулланыла торган процедураларны үткәрүгә суд чыгымнарын каплау өчен җитәрлек акчалар булмау сәбәпле, бурычлыны банкрот дип тану яки банкротлык турындагы эш буенча эшне туктату турында гаризаны суд тарафыннан кире кайтару турында акт кабул ителүе;

7) теркәүче орган карары буенча юридик затны юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан төшереп калдыру һәм «Башкару эшчәнлеге турында» 2007 елның 2 октябрендәге 229-ФЗ номерлы Федераль законның 46 статьясындагы 1 өлешенең 3 яисә 4 пунктында каралган нигез буенча башкарма документны түләтүчегә кире кайтаруга бәйле рәвештә башкару эшен тәмамлау турында суд приставы-башкаручы тарафыннан элек чыгарылган карарның булуы, - оешманың мөлкәте җитәрлек булмау һәм Россия Федерациясе законнарында каралган очракларда аны гамәлгә куючылар (катнашучылар) тарафыннан түләп бетерү мөмкин булмау сәбәпле бюджетка түләүләр буенча түләнмәгән бурыч өлешендә. Теркәү органының «Юридик затларны һәм индивидуаль эшкуарларны дәүләт теркәвенә алу турында» 2001 елның 8 августындагы 129-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә юридик затны юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан төшереп калдыру турындагы карары гамәлгә яраксыз дип танылган очракта, элек әлеге пунктча нигезендә түләтүгә өметсез дип танылган бюджетка түләүләр буенча бурыч бюджет (бухгалтерлык) исәбендә торгызылуы;

8) административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексында каралган очракларда административ җәза билгеләү турында карар чыгарган судья, орган, вазыйфаи зат тарафыннан административ җәза билгеләү турындагы карарны үтәүне туктату турында карар чыгарылуы.»;

3 пунктның «в» пунктчасының унынчы абзацын түбәндәге редакциядә

бәян итәргә:

«административ җәза билгеләү турында, административ җәза билгеләү турындагы карарны үтәүне туктату турында карар чыгарган судьяның, органның, вазыйфаи затның карары.».

2. Административ һәм суд практикасы бүлегенә (Эйдинов Б.Г.) бу борыкны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында теркәүгә алуны тәэмин итәргә.

3. Бу боерыкның үтәлешен котрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче Ж.Й. Әхмәтханов